Торак (торак булмаган) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

“Террорчылыкка каршы тору турында” Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына террорчылыкка каршы тору һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча өстәмә чаралар билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында” 2016 елның 6 июлендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чүпрәле районы прокурорының 2018 елның 20 февралендәге 02-08-02-2018 номерлы протестын исәпкә алып, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 9 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган Торак (торак булмаган) бүлмәне торак булмаган бинага күчерү (күчерү) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 юлының икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче башкарма комитетта шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьләрдә түбәндәге ысулларның берсе белән бирелергә мөмкин (җибәрелгән):

шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);

почта аша.

Гариза һәм документлар, шулай ук, мөрәҗәгать итүче тарафыннан, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга мөмкин.»;

2.6 юлның икенче баганасында:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) күчемсез милек объекты турында бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм бирү тәртибе шушы Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

2.8 нче юл түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Рөхсәт ителми:<br>- торак биналарда сәнәгать производстволарын урнаштыру, шулай ук, «Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында»1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында каралган очраклардан тыш, миссионерлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру;<br>- дини эшчәнлекне тормышка ашыру максатларында торак бинаны торак булмаган бинага күчерү.»; | 17 ст. 3 ө., РФ ТК 22 ст.3.2 ө. |

2.9. юлның өченче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

РФ ТК 17 ст.3 ө., 22 ст. 3 ө., 24 ст. 1 п.;

2.13 юлның икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Электрон рәвештә кергән сорау ял (бәйрәм) көнендә ял (бәйрәм) көненнән соң икенче эш көненә теркәлә.»;

3.4.1.пунктында:

1 пунктчада «күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокуклар» сүзләрен «күчемсез мөлкәт» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) күчемсез милек объекты турында бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә.»;

3.4.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

Росреестр белгечләре җибәргән документлар (белешмәләр) буенча өч эш көненнән дә артмый;

башка тәэмин итүчеләр буенча - ведомствоара гарызнамә органга яисә оешмага кергән көннән алып биш көн эчендә, әгәр ведомствоара гарызнамәгә җавапны әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ һәм төзелеш бүлеге начальнигы Ю.И. Шуркинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкче вазыйфаларын башкаручы М.Р. Гафаров